КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 6 февраль г.Казань № 106

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 15 июнь, 452 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 15 июнь, 452 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 26 март, 275 нче, 2022 ел 22 август, 884 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2023 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга яшь кош-корт сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе»;

әлеге карар белән расланган Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сөтчелек юнәлешендә мини-фермалар төзү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет

системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

4 пунктта:

беренче абзацта «Россия Федерациясе бюджет системасы (алга таба - бердәм портал)» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «30 нчы календарь көннән иртәрәк» сүзләрен «10 нчы календарь көннән иртәрәк» сүзләренә алмаштырырга;

9.4 пунктның «е» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«е) субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе).»;

13 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.»;

әлеге карар белән расланган Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сату өчен билгеләнгән һәм нәселле булган кысыр таналар һәм тана сыерлар сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

4 пунктта:

беренче абзацта «Россия Федерациясе бюджет системасы (алга таба - бердәм портал)» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «30 нчы календарь көннән иртәрәк» сүзләрен «10 нчы календарь көннән иртәрәк» сүзләренә алмаштырырга;

9.4 пунктның «е» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«е) субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе).»;

13 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.»;

әлеге карар белән расланган Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга өч яшьтән өлкәнрәк бияләр асрау чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

4 пунктта:

беренче абзацта «Россия Федерациясе бюджет системасы (алга таба - бердәм портал)» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «30 нчы календарь көннән иртәрәк» сүзләрен «10 нчы календарь көннән иртәрәк» сүзләренә алмаштырырга;

уникенче һәм унөченче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

7 пунктта:

дүртенче абзацта «, әмма бер шәхси ярдәмче хуҗалыкка өч баштан да артык булмаган» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «3 000» саннарын «5 000,0» саннарына алмаштырырга;

13 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау, килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.»;

әлеге карар белән расланган Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга савым сыерларын, ана кәҗәләрне һәм бер яшьтән зуррак булган кәҗә бәтиләрен асрау чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

4 пунктта:

беренче абзацта «Россия Федерациясе бюджет системасы (алга таба - бердәм портал)» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «30 нчы календарь көннән иртәрәк» сүзләрен «10 нчы календарь көннән иртәрәк» сүзләренә алмаштырырга;

уникенче һәм унөченче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

13 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәгалләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.»;

әлеге карарга 2023 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга яшь кош-корт сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен өстәргә (карарга теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 15 июнь, 452 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 6 февраль, 106 нчы
карары редакциясендә)

2023 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга яшь кош-корт сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2023 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга 2023 елның 1 апреленнән 1 июленә кадәр кош-корт (каз, үрдәк, күркә, бройлер чебиләр) сатып алуга тотылган чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр (алга таба - субсидия) бирү механизмын билгели.

2. Субсидия бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен бюджет акчасын алучы буларак бюджет акчасы белән баш эш итүчегә – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Субсидияләр турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

3. Субсидия алучыларны сайлап алу Министрлык тарафыннан шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар тарафыннан җибәрелгән тәкъдимнәрне (гаризаларны) соратып алу ысулы белән, сайлап алу критерийларына һәм гаризалар керүнең чиратлылыгына туры килүдән чыгып үткәрелә.

4. Министрлык бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://agro.tatarstan.ru (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты), сайлап алуны үткәрү срогы башланган көнгә кадәр бер календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

гаризалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның һәм аның муниципаль районнардагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренең (алга таба – Идарәләр) исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почтасы адресын;

бу Тәртипнең 12 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган сайтның домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) битләр күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы затларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

гаризалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 9 пунктындагы беренче абзацы һәм 10 пункт нигезендә гаризалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

гаризаларны кире алу тәртибен, гаризаларны кире кайтару (шул исәптән гаризаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, гаризага үзгәрешләр кертү тәртибен;

әлеге Тәртипнең 11.1 – 11.3 пунктлары нигезендә гаризаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

Бердәм порталда һәм Министрлыкның рәсми сайтында сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соң була алмаган сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасы.

5. Субсидия алучыларны сайлап алу критерийлары:

«Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түләү;

милек хокукындагы һәм (яисә) башка хокуктагы шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлеге булу;

Россия Федерациясе гражданлыгы булу;

әлеге продукцияне турыдан-туры җитештерүчеләр булып торучы Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән кошчылык хуҗалыкларыннан әлеге кош-кортны (ОКВЭД 01.47) сатып алу;

сатып алына торган кош-кортның яше - 30 көннән дә өлкәнрәк түгел;

бер шәхси ярдәмче хуҗалыкка 50 дән 100 башка кадәр яшь кош-корт сатып алу;

сатып алына торган яшь кош-корт партиясенә ветеринария документлары булу.

6. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан гариза бирелә торган датага түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә исәпкә алу буенча электрон хуҗалык кенәгәсендә теркәлгән булу һәм Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру;

шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданга карата Россия Федерациясе законнарында каралган банкротлык процедурасы кертелмәгән;

бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмау;

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмә булмау;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый.

7. Субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлеше сатып алынган яшь кош-кортка түләү буенча факттагы чыгымнар була.

8. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданга бирелгән субсидия күләме 2023 елның 1 апреленнән 1 июленә кадәр кош-корт бәбкәләрен сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = N_1 \times S_1 + N_2 \times S_2 + N_3 \times S_3 + N_4 \times S_4,$$

монда:

$N_1$ - шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан тарафыннан сатып алынган күркәләр саны;

$S_1$ - күркәнең бер башына 200,0 сум исәбеннән субсидия ставкасы, әмма сатып алу бәясенең 50 проценттан артыгы түгел, транспорт чыгымнарын исәпкә алып;

$N_2$ - шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан тарафыннан сатып алынган казлар саны;

$S_2$ - казның бер башына 200,0 сум исәбеннән субсидия ставкасы, ләкин сатып алу бәясенең 50 процентыннан артык түгел, транспорт чыгымнарын исәпкә алып;

$N_3$ - шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан тарафыннан сатып алынган үрдәкләр саны, башлар;

$S_3$ - бер баш үрдәккә 120,0 сум исәбеннән субсидия ставкасы, әмма сатып алу бәясенең 50 процентыннан артык түгел, транспорт чыгымнарын исәпкә алып;

N4 - шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан тарафыннан сатып алынган бройлер чебиләр саны;

$S_4$ – күркәнең бер башына 200,0 сум исәбеннән субсидия ставкасы, әмма сатып алу бәясенең 50 проценттан артыгы түгел, транспорт чыгымнарын исәпкә алып;

9. Субсидия алуга сайлап алуда катнашу өчен шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан http://subsidiya.tatar.ru яки http://subsidiya.tatarstan.ru адресы буенча «Минем субсидияләр» мәгълүмат системасының рәсми сайтында (алга таба – сервис) йә «Минем субсидияләр» мобиль кушымтасында, Бердәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталының (www.gosuslugi.ru) «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла

торган мәгълүмат системаларының мәгълүмат-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләүнең һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» мәгълүмат системасында расланган теркәлү язуыннан файдаланып, шәхси кабинет булдыра, аның түләү реквизитлары һәм почта адресы күрсәтелгән, шул исәптән сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат, сайлап алуда катнашучының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәшәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан турындагы, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан тарафыннан бирелә торган гариза турындагы мәгълүматны һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан турында, сайлап алу белән бәйле булган башка мәгълүматны бастырып чыгару, шулай ук шәхси мәгълүматларны (физик затлар өчен) эшкәртү өчен ризалыгы бирелгән, Министрлык боерыгы белән расланган формада языла торган гариза тутыра һәм түбәндәге документларның сканер ярдәмендә алынган күчермәләрен сервиска кертәләр:

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан 2023 елдан иртәрәк булмаган вакытта Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан бирелгән өземтәләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан тарафыннан мондый документ бирелмәгән очракта, аны Идарә яки авыл яки шәһәр җирлеге башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

әгәр шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен файдалануга рөхсәт бирелгән төрдәге җир кишәрлеге аренда хокукында шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданныкы булса, җир кишәрлегенә аренда шартнамәсе;

2023 елның 1 апреленнән 1 июленә кадәр финанс елда кошчылык хуҗалыкларыннан яшь кош-корт бәбкәләрен сатып алуга чыгымнарны раслый торган документлар (сату-алу шартнамәләре, кабул итү-тапшыру актлары, контроль-касса техникасын кулланып басылган касса чегы, яшь кош-корт бәбкәләрен сатып алу көнендә рәсмиләштерелгән наклад һәм ветеринария документлары);

авыл хуҗалыгы кошларын үрчетү белән шөгыльләнүче сатучы оешманы теркәү турында таныклык.

Сервиста автомат режимда алына торган мәгълүматлар һәм документлар:

шәхси ярдәмче хуҗалык башлыгының паспорт мәгълүматлары (гомуми мәгълүматлар һәм яшәү урыны бүлекләре);

шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуның электрон хуҗалык кенәгәсеннән сатып алынган яшь кошларны исәпкә кую фактын раслый торган өземтә;

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмавын раслый торган салым органының белешмә кәгазе.

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан түбәндәгеләргә хокуклы:

гаризаларны кабул итү тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта гаризаны кире алырга;

кирәк булганда, гаризалар кабул итү өчен билгеләнгән срокта гаризаны кабат бирергә, шул ук вакытта гариза кергән көндә чират тәртибендә теркәүгә алына.

10. Сервиста шәхси кабинетны мөстәкыйль ачу һәм (яки) гариза булдыру өчен техник мөмкинлекләр булмаган очракта, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан Идарәгә яки башкарма комитетка файдалану мөмкинлеге булган шәхси кабинет аша шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан исеменнән гариза бирү өчен Идарәгә яки башкарма комитетка мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Моның өчен шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданинга бу Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән документларны Идарәгә яки башкарма комитетка тапшырырга һәм түбәндәге документларны күрсәтергә кирәк:

паспорт;

салым органында исәпкә куелу турында таныклык күчермәсен;

индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ.

11. Гаризаны кире кагу турында карарлар кабул итү, субсидия бирү турында карар түбәндәге тәртиптә гамәлгә ашырыла:

11.1. Идарә гаризалар кабул итү турында игълан итүдә күрсәтелгән сайлап алуны уздыру срогы тәмамланган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган биш көнлек чорда:

шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарны тикшерә һәм тәкъдим ителгән документларны аларның сайлап алуны үткәрү турында игълан итүдә билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килү-килмәвенә карый, Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарның гаризаларын карау нәтиҗәләре турында реестрны Министрлык боерыгы белән расланган рәвештә төзи һәм Министрлыкка Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы аша җибәрә;

Министрлыкка шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидияләр турында тиешле исәп-хисаплар тапшыра.

11.2. Министрлык:

гаризалар кабул итү срогы тәмамланган көннән 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, Идарәләр тарафыннан тапшырылган реестрлар нигезендә Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарның гаризалар бирү чираты тәртибендә сайлап алу нәтиҗәләре турында (сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләү турында йә гаризаны алмау турында) җыелма реестр төзи;

сайлап алуда җиңүчеләр билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, бердәм порталда һәм Министрлыкның рәсми сайтында түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыра:

гаризаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны;

гаризалары каралган шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар турында мәгълүмат;

гаризалары кире кагылган шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар турында мәгълүмат, аларны кире кагу сәбәпләрен, шул исәптән мондый гаризалар туры килми торган сайлап алуны үткәрү турында игъланнар нигезләмәләре күрсәтеп;

субсидия алучының (алучыларның) исеме һәм аларга бирелә торган субсидиянең күләме.

11.3. гаризаларны карап тикшерү стадиясендә гаризаны кабул итмәү өчен түбәндәгеләр нигез була:

шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданның әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан тарафыннан тапшырылган гаризаның һәм документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән гаризаларга карата таләпләргә туры килмәве;

шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан биргән мәгълүматның, шул исәптән шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданның яшәү урыны турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан тарафыннан гариза бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яисә) вакыттан соң гариза бирү;

шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданның әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән критерияләргә туры килмәве;

бюджет йөкләмәләре лимитының сарыф итеп бетерелүе.

11.4. Министрлык:

бердәм порталда һәм Министрлыкның рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштырылган көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча субсидия алучыларга субсидияләр бирү турында карар кабул итә, ул, субсидияне алучы һәр кешегә карата субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсен күрсәтеп, Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә;

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга бирелә торган субсидияләр турында җыелма белешмә-исәп- хисап Идарәләре тарафыннан тапшырылган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетыннан акчалар күчерүне Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган Идарәләрнең шәхси счетларына күчерә.

11.5. Идарәләр үз шәхси счетына бюджет акчасы кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә субсидияләрне аларны алучылар өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетларына күчерә.

12. Субсидия бирү нәтиҗәсе - 2023 елның 1 апреленнән 1 июленә кадәр субсидияләр катнашында сатып алынган яшь кош-корт: каз, үрдәк, күркә, бройлер чебиләре.

13. Субсидия алучы Министрлыкка субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү турында, субсидия алу елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән типлаштырылган килешү формасы буенча хисап тапшыра.

14. Бирелгән субсидияләр субсидияләр субсидияләр алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча, шулай ук субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә җитмәгән очракта, Идарәнең тиешле

таләбе алынган көннән алып 60 көн эчендә Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

15. Әлеге Тәртипнең 14 пунктында күрсәтелгән акчаның Татарстан Республикасы бюджеты керемено ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә календарь көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә Министрлык тарафыннан мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

16. Министрлык субсидия алучыларның субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

17. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы Министрлыкка һәм гражданнар тарафыннан Идарәгә тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен Идарәгә тиешле вазыйфаи затларга һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга җаваплылык йөкләнә.

18. Бюджет акчасыннан файдалануны контрольдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

---